| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«27» февраль 2026 ел Алабуга шәһәре № 47

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 23 сентябрендәге 139 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга шәһәр прокуроры протестын караганнан соң, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2011 елның 23 сентябрендәге 139 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 өлешне түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиленә, прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына аны коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, башка муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел хокук бозуларны кылу фактлары, белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, ялган белешмәләр тапшыру йә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру фактлары турында хәбәр иткән муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов